РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
АЛЬМЕТЬЕВСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ӘЛМӘТ
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

«1» февраля 2021 ел г. Альметьевск № 90

**Әлмәт муниципаль районы Башкарма комитетының «2020-2022 елларга Әлмәт муниципаль районында хезмәт шартларын яхшырту һәм саклауның муниципаль программасын раслау турында» 2020 елның 13 апрелендәге 474 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында**

Төзәтүләр тәртибендә,

БАШКАРМА КОМИТЕТ КАРАР БИРӘ:

1. «Әлмәт муниципаль районы Башкарма комитетының «2020-2022 елларга Әлмәт муниципаль районында хезмәт шартларын яхшырту һәм саклауның муниципаль программасын раслау турында» 2020 елның 13 апрелендәге 474 номерлы карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

карарга 1 нче кушымтада:

1.1. 2020-2022 елларга Әлмәт муниципаль районында хезмәт шартларын яхшырту һәм хезмәтне саклау буенча муниципаль программа паспортында «Программаны финанслау күләмнәре һәм чыганаклары» юлын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

| | |
|---|---|
| Программаны финанслау күләмнәре һәм чыганаклары | Муниципаль программаны финанслауның гомуми күләме Әлмәт муниципаль районы бюджеты хисабына 0 сум тәшкил итә, шул исәптән:<br>2020 елда - 0 сум;<br>2021 елда - 0 сум;<br>2022 елда - 0 сум.<br>Искәрмә: күрсәтелгән чыганаклардан бүлеп бирелгән акчалар күләме фаразлау характерында була һәм, программалы чаралар исемлеген, аларны гамәлгә ашыру срокларын һәм этапларын ирешелгән нәтиҗәләр нигезендә төгәлләштерүне исәпкә алып, билгеләнгән тәртиптә җирле бюджет мөмкинлекләрен исәпкә алып, ел саен төзәтмәләр кертергә тиеш. |

Зак. № 305-2000

1.2. 2 бүлекнең «Программа бүлекләрен бәяләүнең максатлары, бурычлары, индикаторлары һәм Программа чаралары буенча финанслау» таблицасында:

- 7,8,9 графаларында, «10» санын «0» санына алмаштырырга;
- 10 нчы графада «60,0» санын «0» санына алмаштырырга.

1.3. «Программаны финанслау күләмнәре һәм чыганаклары» 3 бүлеген түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Муниципаль программа чаралары Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы бюджеты акчалары исәбеннән гамәлгә ашырыла. 2020-2022 елларга программаны финанслау күләме 0 сум тәшкил итә, шул исәптән:

2020 елда - 0 сум;

2021 елда - 0 сум;

2022 елда - 0 сум.

Искәрмә: финанслау күләмнәре фараз характерында һәм, җирле бюджет мөмкинлекләрен исәпкә алып, ел саен төзәтмәләр кертелергә тиеш».

1.4. 2020-2022 елларга Әлмәт муниципаль районында хезмәт шартларын яхшырту һәм хезмәтне саклау буенча муниципаль программага1 нче кушымтада «Программа чаралары исемлеге» таблицасындагы «Җирле үзидарә органнары җитәкчеләрен һәм белгечләрен хезмәтне саклау буенча укытуны оештыру» 1 нче юлның 6 нчы графасында» «60,0» санын «0» санына алмаштырырга.

2. Район Башкарма комитетының Хокук идарәсенә (Ханнанова Ә.Б.) әлеге карарны «Альметьевский вестник» газетасында бастырып чыгарырга, Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (PRAVO.TATARSTAN.RU) урнаштырырга.

3. Әлеге карар рәсми басылып чыкканнан соң үз көченә керә.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны район Башкарма комитеты җитәкчесенең төзелеш буенча урынбасары Д.В. Косаревка йөкләргә.

Район
Башкарма комитеты җитәкчесе — М.Н. Гирфанов

ПРОТОКОЛЬНЫЙ ОТДЕЛ
БЕРКЕТМӘ БҮЛЕГЕ